КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 декабрь г.Казань № 1565

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хосусыйлаштыру процессында төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрдәге Татарстан Республикасы милкендә булган өлешләр белән идарә итү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 24 март, 167 нче карары белән расланган Хосусыйлаштыру процессында төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрдәге Татарстан Республикасы милкендә булган өлешләр белән идарә итү тәртибенә, 3 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеше аның устав капиталының 100 процентын тәшкил иткән акционерлык җәмгыятенең 100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган очракта хуҗалык җәмгыяте белән идарә итүче югары орган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 8 апрель, 198 нче карары белән расланган Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеше аның устав капиталының 100 процентын тәшкил иткән акционерлык җәмгыятенең 100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган очракта хуҗалык җәмгыяте белән идарә итүче югары орган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыру тәртибенә, 3 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин